РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.04.2021 г.** **№ 18**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм билгеләү буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы № 272 «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) террорчылыкка каршы яклануга карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлыгы паспортларын раслау турында» гы карары нигезендә һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, халыкны террористик актлардан яклау, кешеләр күп була торган объектларны саклау максатларында карар бирәм:

1. Кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү буенча комиссия төзергә (алга таба – Комиссия).

2. 1 нче кушымта нигезендә кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне расларга.

3. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм билгеләү буенча ведомствоара комиссия составын расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Район башлыгы Г.Г.Хәкимов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы башлыгының
2021елның 9 апрелендәге
18 номерлы карарына

**Кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия), эшчәнлеге кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләштерүгә юнәлдерелгән, даими эшләүче координация органы булып тора.

## 2. Комиссия төзү максаты

Комиссияне булдыруның максаты – кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләүне, потенциаль куркыныч дәрәҗәсен һәм кешеләр күпләп була торган урыннарда террорчылык актларын һәм аларның мөмкин булган нәтиҗәләрен исәпкә алып, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә дифференциацияләнгән таләпләрне билгеләү өчен оештыру.

## 3. Комиссия Вәкаләтләре

Комиссия хокуклы:

3.1. Кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү.

3.2. Кеше күп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актларын төзү.

3.3. Кешеләр күпләп була торган урынның куркынычсызлык паспортын төзергә һәм аны актуальләштерергә.

3.4. Кешеләр күпләп була торган урыннарны террорчылыкка каршы саклауны тәэмин итү чараларын билгеләү.

3.5. Кешеләр күпләп була торган урыннарны террорчылыкка каршы яклауга карата таләпләрнең үтәлешен планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрергә.

## 4. Комиссиянең эш тәртибе

4.1. Комиссия рәисеннән, рәис урынбасарларыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

4.2. Комиссияне комиссия рәисе җитәкли.

Комиссия рәисе булмаганда, рәис вәкаләтләрен аның урынбасарларының берсе башкара.

4.3. Комиссия Рәисе:

а) Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Көн тәртибен билгели. Аның утырышларында мәсьәләләрне карау сроклары һәм тәртибе;

б) Комиссия утырышларын үткәрүне башлап җибәрә;

в) Комиссия утырышы эшен алып бара;

г) кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актларына һәм Комиссия вәкаләтләрен үтәүгә кагылышлы башка документларга имза сала.

4.4. Комиссия составына кертелә:

а) кешеләр күпләп була торган урын милекчесе яки башка закон нигезендә кешеләр күпләп була торган урынны кулланучы зат;

б) территориаль куркынычсызлык органы вәкилләре;

в) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органнары вәкилләре. Кирәк булган очракта, Комиссия эшенә кешеләр күпләп була торган урын чикләрендә яки аңа якын урнашкан объектларның милекчеләре вәкилләре җәлеп ителә.

4.5. Комиссиянең эш нәтиҗәләре кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү акты белән рәсмиләштерелә, 5 нөсхәдә төзелә, комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм кешеләр күпләп була торган урында куркынычсызлык паспортының аерылгысыз өлеше булып тора.

4.6. Кешеләр күпләп була торган һәр урынга, аны тикшерү һәм категорияләгәннән соң, комиссия тарафыннан куркынычсызлык паспорты төзелә. Ул 5 нөсхәдә төзелә, территориаль Куркынычсызлык органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы җитәкчеләре белән килештерелә һәм Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы башлыгы
2021елның 9 апрелендәге
18 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм билгеләү буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| А.Ф. Каюмов | - Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе, ведомствоара комиссия рәисе |
| М.Л. Халиков | - Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары; |
| Л.А. Мингазов | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге башлыгы, ведомствоара комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча); |
| К.М. Тухфатуллина | - балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеге һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча әйдәп баручы белгеч-инспекторы, ведомствоара комиссия секретаре. |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| М.И. Газизов | - Әтнә районы прокуроры урынбасары (килешү буенча); |
| И.Ш. Яруллин | - «Әтнә РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча);); |
| Р.Н. Гарипов | - Гражданнар оборонасы өлкәсендә (Әтнә районы буенча) һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты (килешү |
| Л.Т. Гарипов | - Әтнә районы Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы; |
| Г.Р. Галяутдинова | - Әтнә районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы; |
| Г.Д. Хакимзянова | - Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эшләре буенча ярдәмчесе; |
| Г.Р. Мухамедзянова | - «ТАТМЕДИА» АЖ филиалы «Әтнә таңы» газетасы редакциясе баш мөхәррире (килешү буенча). |